КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 сентябрь г.Казань № 865

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2020 елның 18 сентябрендәге ПУ-589 номерлы Указын тормышка ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасы турында» 2020 елның 18 сентябрендәге ПУ-589 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетын бетерү буенча ликвидацияләү комиссиясен төзергә һәм аның составын (карарга теркәлә) расларга.

2. Ликвидацияләү комиссиясенә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, ликвидацияләү чараларын үткәрүгә чыгымнар сметасын расларга;

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мөлкәтен инвентарьләштерергә;

Татарстан Республикасының бетерелә торган Социаль-икътисадый мониторинг комитеты хезмәткәрләренә эштән азат ителәчәкләре турында шәхсән билгеләнгән тәртиптә кисәтү ясарга;

барлык ликвидацияләү чараларын үтәүне һәм эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының ликвидацияләү балансын, шулай ук ликвидацияләү турындагы хисапны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга кертергә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына түбәндәгеләрне әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә:

14 көн эчендә:

түбәндәге актлар проектларын:

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә, аның структурасына һәм Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының тапшырылган функцияләре буенча хезмәткәрләрнең иң чик санына үзгәрешләр кертү турындагы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларын Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 18 сентябрендәге ПУ-589 номерлы Указына һәм бу карарга туры китерү турындагы;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары санын билгеләү турындагы тәкъдимнәрне;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Президенты актларына тиешле үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне.

4. Татарстан Республикасының бетерелгән Социаль-икътисадый мониторинг комитеты хезмәткәрләре барлык ликвидацияләү чаралары тәмамланганга кадәр үзләренә йөкләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыруны дәвам итә һәм Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәдә һәм тиешле вазыйфаи тәгълимнамәләрдә беркетелгән тиешле идарә итү өлкәләрендәге эшләр торышы өчен җавап бирә дип билгеләргә.

5. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары:

«Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче;

«Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турында» 2006 ел, 16 февраль, 59 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2006 ел, 7 июнь, 282 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 карарына үзгәреш кертү хакында» 2008 ел, 5 декабрь, 858 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 ел, 24 февраль, 98 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2011 ел, 10 июнь, 470 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 13 август, 673 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 17 август, 716 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 7 март, 153 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 25 ноябрь, 924 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2014 ел, 7 июнь, 387 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 27 ноябрь, 897 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 8 апрель, 202 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 3 август, 531 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 24 ноябрь, 873 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 4 июль, 459 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 15 ноябрь, 876 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 27 ноябрь, 1052 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 11 июнь, 456 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 26 декабрь, 1232 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2019 ел, 22 март, 210 нчы;

«Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 март, 232 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты коллегиясе составын раслау турында» 2019 ел, 28 март, 232 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 14 август, 682 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты мәсьәләләре» 2005 ел, 3 август, 383 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 17 август, 696 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче карарыдагы икенче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарының «Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы турында» 2010 ел, 31 март, 205 нче карарындагы 5 нче пунктының өченче абзацы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елда социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмат ресурсы турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 24 декабрь, 1213 нче карарындагы 7 нче пунктының тугызынчы абзацы.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры М.Р.Шаһиәхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 сентябрь, 865 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетын
бетерү буенча ликвидация комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Семенова Ольга Юрьевна | Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе |
| Биккинәев Рамил Шамил улы | Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының юридик секторы мөдире, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Вәлитова Альбина Әлфир кызы | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы идарәсе аппаратын финанслау бүлеге башлыгы |
| Галиев Артур Ирек улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Галимов Айнур Газинур улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |
| Насыртдинов Олег Рәшит улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанслар һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы урынбасары |
| Олонова Юлия Николаевна | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары |
| Сәйдәшева Лилия Илдус кызы | Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының финанс бүлеге башлыгы |
| Сарипова Венера Тәбриз кызы | Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы төп киңәшчесе |
| Шәрәфетдинов Рәис Мифтах улы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының эшләр идарәчесе |

| | |
|---|---|
| Щетинина Татьяна Геннадьевна | Татарстан Республикасы Социаль-икътисадый мониторинг комитетының мәгълүмат ресурслары һәм технологияләр бүлеге башлыгы. |